| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 35 « 01 » октябрь 2019 ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Болгар шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

«2020 елда «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?

**Җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:**

- Некрасов ур., Дзержинский ур., Октябрь ур., Нариманов ур., Пушкин ур., Солнечная ур., Матросов ур., З.Космодемьянская ур, Ленин ур, Нагаев ур. суүткәргеч челтәрен реконструкцияләү, задвижкалар урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карарны «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә 2019 елның 2 октябреннән мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2019 елның 2 октябреннән рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://spasskiy.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

Болгар шәһәре
Башкарма комитет җитәкчесе А.М.Тюленев

БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ